# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

27 ноябрь, 2024 ел №2

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Починок-Шәмәрдән авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Починок-Шәмәрдән авылында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Кукмара районы Ядегәр авыл җирлегенең Починок-Шәмәрдән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз әниләр, 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Починок-Шәмәрдән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Починок-Шемордан авылындагы юлларны кышкы-җәйге тоту һәм проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

(Починок-Шемордан авылының Совет урамы буенча вак таш белән капланган юллар төзү һәм ремонтлау проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү);

(Починок-Шемордан авылы урамнарына асфальт салу, проект-смета документациясен эшләү, технадзорны гамәлгә ашыру һәм экспертиза үткәрү, килешү буенча түләү);

2) тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Починок-Шемордан авылында энергия саклаучы лампаларны, светодиодлы яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм тоту)ремонтлау;

3) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр) (төзекләндерү, чишмәләрне тоту, проект-смета документациясе, технадзорны

гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәләрне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре);

4) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантларын, комплектлаучы детальләрне сатып алу һәм урнаштыру, комплектлаучы детальләрнең проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

5) су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Починок-Шемордан авылының Совет урамы буенча су белән тәэмин итү трассасын ремонтлау, су күтәрү манарасы өчен насос сатып алу), проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

6) ремонтлау, коймалар төзү, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (Починок-Шемордан авылындагы зиратларны саклау, материаллар, кораллар сатып алу һәм коймаларны урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү);

7) торак пункт территориясен төзекләндерү (төзелеш, инвентарь сатып алу, халыкның күпләп ял итү урыннарын ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү));

3. Әлеге карарны Ядегәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ядегәр авыл җирлеге
башлыгы: А.Н.Фәйзуллин